КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1043

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 53 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләләрне исәпкә алу тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен яшь гаиләне исәпкә кую турында карар кабул итү өчен түбәндәге документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) кирәк:»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе гражданының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм вакытлыча тору урыны буенча теркәлүе йә теркәлмәве турында мәгълүматлар;»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) теркәлү урыны буенча билгеләнә торган торак урынга, шулай ук соңгы биш елда милектә булган башка торак урыннарга хокукны билгели торган документларның күчермәләре (социаль наем шартнамәсе, хосусыйлаштыру

шартнамәсе, сату-сатып алу шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе, милек хокукын теркәү турында таныклык яки Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә һ.б.), индивидуаль торак төзелеше объектларында яшәүчеләр өчен – әлеге объектка кадастр паспорты;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) 2000 елның 1 гыйнварыннан булган чорга Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә мөлкәтне алу буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында өземтәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән белешмә кәгазьләре) – торак урында теркәлгән барлык гражданнар өчен;»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлү турында мәгълүматлар;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 1, 2, 4 – 7, 9, 10, 12, 13, 16 пунктчаларында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»;

8 пунктта:

беренче абзацта «бирелә» сүзен «кирәк» сүзенә алыштырырга;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан төзелеше төгәлләнмәгән индивидуаль торак йорт һәм җир кишәрлеге буенча өземтәләр.

Җир кишәрлеген арендалаган очракта, җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын һәм аренда түләвенең исәп-хисабын теркәп, законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән аренда шартнамәсе кертелә;»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) торак йорт төзүгә рөхсәтнамә яки планлаштырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү турында хәбәрнамә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»;

9 пунктта «календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә» сүзләрен «25 эш көне эчендә» сүзләренә алыштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә» сүзләрен «20 эш көне эчендә» сүзләренә алыштырырга;

12 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңадан теркәлү өчен ел саен 1 апрельгә кадәр яшь гаилә җирле үзидарә органына әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы 3, 11, 14, 15 пунктчаларында һәм 8 пунктның 5, 8 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган мәгълүматларны) кертә.»;

өченче абзацта «яшь гаилә календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә» сүзләрен «яшь гаилә 10 эш көне эчендә» сүзләренә алыштырырга, «Җирле үзидарә органы календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә» сүзләрен «Җирле үзидарә органы биш эш көне эчендә» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзацта «календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «20 эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы 4, 13, 16 пунктчаларында һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы 2, 3 пунктчаларында күрсәтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөстәкыйль рәвештә соратып алына.»;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

«Гаризага Тәртипнең 7 пунктында каралган документлар теркәлә.» дигән абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризага Тәртипнең 7 һәм 8 пунктларында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) теркәлә.»;

«Үзгәрешләр булган очракта, алар кертелгән документларны календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә җирле үзидарә органына кертү кирәклеге турында беләм.» абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзгәрешләр булган очракта, алар кертелгән документларны 25 эш көне эчендә җирле үзидарә органына кертү кирәклеге турында беләм.»;

«Ф.И.О.» аббревиатурасын «фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар яшь гаиләгә индивидуаль торак йорт төзелешен һәм (яки) реконструкциясен тәгәлләүне тәэмин итү юлы белән торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтелгән очракта кертелә.»;

Тәртипкә 2 нче һәм 3 нче кушымталарда «Ф.И.О.» аббревиатурасын «фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин